2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авылы җирлеге Улаклы Чишмә авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

03 декабрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васльевка авыл җирлегенең Улаклы Чишмә авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең Улаклы Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: урам яктырткычларын норматив хәлгә китерү (материаллар сатып алу), смета төзү өчен түләү; су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү (материаллар сатып алу), смета төзү өчен түләү?”.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Улаклы Чишмә авылы, Үзәк урамы 32а нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Васильевка авыл җирлеге башлыгы Ш.М. Касыймуллин